**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә торак пунктында**

**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“03” ноябрь 2020 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Өҗемавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Өҗем авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №105 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Территорияне төзекләндерү:
   - Таш-Чишмә авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эш өчен түләү);

2) Таш-Чишмә торак пунктында янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
   - янгын гидрантына кран сатып алу;

3) Авыл эчендәге куперне сүтеп, яңадан кору;

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Таш-Чишмә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Таш-Чишмә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗемавыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.